# ЧИШМӘ БАШЫ

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе
НОЯБРЬ
2024 ел



***Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

## Газетаның сәхифәләре:

* Бәйрәм белән, әниләр!
* Кайсы, кайда яши?
* Бергә иҗат итәбез.
* Бик күп беләсем килә!



***Баш мөхәррир:***
***музыка җитәкчесе –***
***Хөсәенова Гөлшат Фердинант кызы***

# БӘЙРӘМ БЕЛӘН, ӘНИЛӘР!

Безнең балалар бакчасында Әниләр көне ел саен бик күңелле, җылы һәм кызыклы үтә.

Бу матур көнгә багышланган төрле чаралар үткәрелә, аларның төп максаты - мәктәпкәчә яшьтәге балаларда әниләргә карата мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү, балаларның иҗади сәләтләрен үстерү һәм бәйрәм атмосферасы тудыру. Бу бәйрәмгә бер атна кала әзерләнә башлыйлар: якын һәм кадерле кеше - әни турында әңгәмәләр үткәрелә, әниләр турында нәфис әсәрләр укыла, матур җырлар һәм шигырьләр, биюләр өйрәнелә, яраткан әниләренең портретлары ясала һәм аларга бүләкләр әзерләнә.

Быел да Халыкара Әниләр көне бәйрәме уңаеннан балалар бакчасында Әниләр көненә багышланган музыкаль-әдәби күңел ачу чарасы узды. Балалар үз куллары белән открытка әзерләделәр. Сезнең һәрчак сәламәт, актив булуыгызны, балаларыгызның уңышларына чын күңелдән сөенеп яшәвегезне телибез!

***Иң изге теләкләр белән,***
***"Кояшкай" балалар бакчасы мөдире***
***Мостафина Рима Галип кызы***

Уен – баланың тормышка
әзерләнү күнекмәсе ул.
П.Ф.Лесгафт

Мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең төп бурычы балаларны рухи яктан бай, физик яктан сәламәт итеп үстерү. Алар төрле юллар белән тормышка ашырыла. Ә шулар арасында иң әһәмиятлесе – уеннар.

Уен ярдәмендә балаларда зирәклек, оешканлык, коллективта үзеңне тота белү, җитезлек кебек матур сыйфатлар тәрбияләнә. Уеннарның бала психикасына уңай йогынтысы турында күренекле педагоглар Л.С.Выготский, А.Н.Леонтьев, Д.Б.Эльконин, А.В.Запорожец, А.П.Усов та үз хезмәтләрендә язганнар.



Яшь буын тормышның төрле җайсызлыкларына бирешмәскә, уңышсызлыкларыннан җебеп төшмәскә тиеш дибез. Ә моңа яшьтән үк балаларның төрле уеннар уйнаулары аша ирешергә мөмкин.

Билгеле булганча, балалар бакчаларында нәниләрнең күптөрле эшчәнлеге уеннар ярдәмендә оештырыла дип ассызыклап үтәм. Ул баланы мавыктыра, аңа куаныч китерә.

Дидактик уеннар – балаларны уйланырга, эзләнергә, фикер тупларга, берләштерергә, күнекмәләрне, гадәтләрне тормышта кулланырга өйрәтүче һәм тәрбия бирүче көчле чараларның берсе.

Балаларны әйләнә-тирә дөнья белән таныштыру максатыннан кечкенәләр төркеме өчен “Кайсы, кайда яши?” исемле дидактик уен тәкъдим итәсем килә.

Уенның максаты – балаларның кыргый җәнлекләр турында белемнәрен ныгыту, аларның кайда яшәүләрен, нәрсә белән тукланулары турында аңлату.

Әлеге уенны әзерләү өчен мин фетрдан җирлек, урман күренеше, җәнлекләрне, аларның яшәү урыннарын булдырдым. Уенда һәрбер элемент кулдан тегелгән, җәнлекләргә ныклык өчен ябыша торган кәгазь, ояларына махсус төймәләр урнаштырдым.

Балалар әлеге уенны аеруча кызыксынып, яратып уйныйлар. Бу уен аша балаларда урман җәнлекләренә карата михербанлылык, табигатькә сакчыл караш тәрбияләнә.

*Тәрбияче - Җәләлиева Айгөл Госман кызы*

БЕРГӘ ИҖАТ ИТӘБЕЗ!

***Әниләргә иң кадерле бүләк!***











***Тәрбияче – Шәкүрова Рокыя Сәүбән кызы***

# БИК КҮП БЕЛӘСЕМ КИЛӘ!

## ТАБЫШМАКЛАР

1.Чәчәге агачында, алмасы тамырында.



2. Алгы тәпие кыска, чабарга ул бик оста.



3. Лампа түгел – яктырта, мич түгел – җылыта.










1. Соры тунын сала да, ак тунын кия кышка.
2. Язның беренче ае.
3. Кояш түгел – яктырта, өйгә нурлар тарата.
4. Үзе дулый, үзе котыра, бөтен җирне кар белән тутыра.
5. Яшел, ә алан түгел, ак, ә кар түгел, бөдрә, ә чәче юк.

***Тәрбияче – Хөсәинова Рәзинә Равил кызы***